Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2020 ел №400

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 4 июлендәге 308 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 21 июлендәге 02-01-25/2020 номерлы норматив хокукый актны үзгәртү турында Әлмәт шәһәр прокуроры таләбен карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советыныж 2013 елның 4 июлендәге 308 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга «Норматив хокукый акт проектын җирле үзидарәнең тиешле органына кертү тәртибе» кушымтасындагы 4 бүлегенең 4.5 пунктындагы беренче абзацында «танырга хокуклы» сүзләрен «тану турында карар кабул итә» сүзләренә алмаштырырга;».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов